«АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»
№42 (503) | **27 октябрь – 2 ноябрь** 2023 ел

# Зифа Кадыйрова: «Бәхетем – балаларымда»

## Күркәм юбилее уңаеннан, язучыда кунакта булдык.



Фото – З.Кадыйрованың шәхси архивыннан

Гөлназ **Хәбибуллина**

**Зифа Кадыйрова Чаллы шәһәреннән берничә чакрым гына ераклыкта урнашкан бакча йортында яши. Көзге бакчага соклanып йөргәч, баллап чәй эчтек, дөнья хәлләре һәм иҗат турында сөйләштек.**

### «Мин хәзер дә шул ук Зифа Кадыйрова»

**– Зифа ханым, бу элек янган бакча өегез урынында төзелгән яңа йортмы?**

– Әйе, 2019 елда янгын чыгып, йортсыз калдык. Бөтен архивым янып бетте... Бурычка бата-бата булса да 2020 елда яңа йорт күтәрә башладым. Җирсез тормышымны күз алдына китерү мөмкин түгел иде. Үз йортың белән яшәү рәхәт – балалар, оныкларым килә...

**– Сез менә гап-гади кеше булып яшәдегез дә, популяр шәхескә әверелдегез. Өегездән дә кеше өзелми. Мондый тормыш сезне арытмыймы?**

– Мин шундый тормышка ияләшкән кеше. Без үскәндә әни өй янында бакча уртасына мич чыгартып, көне буе шунда чәй кайнатып, аш пешерә, ап-ак итеп керләр юа, аларны матур итеп бауга элә иде. Үткән бер кеше, безгә кереп, чәй эчеп китә иде. Әнине мин 1991 елда үз яныма – Чаллыга алып килдем. Ул беренче каттан фатир алды. Күршеләр өйләренә кайтканда әнигә кереп чәй эчеп чыга торган иде. Күп итеп пирожки пешереп куя да: «Әнә шул-шул кайтып килә, кая, бирим әле», – дип, үзе кешенең каршына йөгереп чыга. Шулхәтле кунакчыл булды әнием.

Үзем тормышка чыккач, бездә сеңлем яшәде, аннан иремнең яшүсмер энесен үзебезгә алдык. Мин – әниемне, әни үз энисен алып килде. Үзебездә – ике бала, «малосемейка»да торабыз. Күршеләр белән ике арадагы ишек беркайчан бикләнмәде. Балаларның бөтен сыйныфташлары бездә булды. Гомер буе шулай яшәдек. Мин хәзер дә шул ук Зифа Кадыйрова. Китап яза башлап популярлыкка ирешүем белән миндә берни дә үзгәрмәде.

**– Зифа апа, туган якларыгыз, балачагыгыз турында сөйләгез әле.**

– Мин тумышым белән – Башкортстанның Учалы районы Ахун авылыннан. Әти белән әни без кечкенә чакта аерылышты. Безне – балаларны бүлделәр. Әти холыксызрак иде. Минем тормыш юлым сикәлтәле булды. Әсәрләремдәге сюжетлар да күбесе үз тормышымнан алынган. Авылдан 19 яшемдә чыгып киттем. Яшәргә тырыштык, югалмадык. Зур, һыклы гаилә кору турында хыялландым. Мин гомер буе бәхетле хатын булып яшәдем, ирем белән бик матур пар идек. (Зифа ханымның ире Марсель Кадыйров 2013 елда вафат була. – *Автор*). Аллага шөкер, балалар да парларыннан уңды. Киявем тыныч, балаларны ярата, улым үз гаиләсе өчен янып тора. Әтиләре балаларыбызга: «Сез әниегезне чыгып киткәндә һәм кайтып кергәч кочаклап үбәргә тиешсез», – дип әйтә торган иде. Улым Русланга 45 яшь тула, ул килә дә мине кочаклап үбә. Кызым Регина да шулай. Алар балалыкларын саклап калды, явызланмады. Киленем дә «әни» дип кенә тора. Ул яктан хәзер бөтен бәхетем – балаларымда.

### «Беркемгә үпкәм юк»

**– Зифа ханым, җитди авырып алдыгыз, дип беләм. Хәзер сәламәтлегегез ничек?**

– Начар дисәм – начар, әйбәт дисәм – әйбәт. 65 яшемне күрер өчен (язучының туган көне – 7 октябрьдә. – *Автор*), операциядән баш тарттым.

**– Йөрәккәме?**

– Әйе. Күп нәрсә кәефтән дә тора, төшенкелек чиргә китерә. Мин, Аллага шөкер, бүгенге көндә бар нәрсәдән канәгать. Шуңа күрә чир әлегә чигенде, әмма ул беркая да китмәде.

**– Авыру сәбәпле иҗатта да пауза булып алгандыр?**

– Башлаган китабым тәмамланмаган килеш калды... Майдан бирле каләм тоткан юк.

**– Көндәлек эшләр белән шөгыльләнгәндә әсәр турында уйлап йөрисезме?**

– Баш ял итми, ул гел эшләп тора. Кемнәрдер: «Син язучы түгел», – ди инде миңа. Мин үземне язучы дип санамыйм да. Язу ул – күңел халәте. Күңелемдәгене башкаларга да җиткерәсем килә. Замана тудырган сораулар җавап эзләргә мәҗбүр итә. Бүгенге көнне алсак, шушы махсус хәрби операция проблемалары гына да шулхәтле күпкырлы. Алар әле тагын да өстәлә торачак.

**– Зифа ханым, китапларыгызны чират торып алсалар да, әсәрләрегез театр сәхнәләреннән төшмәсә дә, сез каләмдәшләрегез тарафыннан кыерсытуларга дучар булган язучы.**

– Хәзер мине таптаучылар кимеде инде. Зур язучылар кул биреп исәнләшә. Чөнки мин нәрсә генә ишетсәм дә, берсенә дә җавап бирмәдем, бәхәскә кермәдем. Тукай да бөтен кешегә ярап бетәрлек итеп яза алмагандыр. Беркемгә үпкәм юк.

Нигә Язучылар берлегенә кермәвем турындагы сорауны еш бирәләр. Анда чакырмадылар түгел, чакырдылар. Чакырганда бара алмадым. Ә хәзер, яза-яза, күп нәрсәне аңлыйм. Татарстан Язучылар берлегенә кирәрлек китабым язылмаган әле минем. Әдәбиятка соң килдем. Башланган ике әсәрем бар, аларны тәмамлагач, бәлки уйлап карармын.

### «Халыктан рәхмәт сүзләрен күп ишетәм»

**– Сез ничек уйлыйсыз, бүген язучыларга игътибар җитәме?**

– Миңа җитә. Калганнар өчен җавап бирә алмыйм. Мин алар арбасында түгел, минем үземә бер арба.

**– Китап чыгару бик зур чыгымнар сорый. Акча ничек җиткерәсез?**

– Баштагы чорларда бик кыен булды. Кредитлар алырга туры килде. Мин халыкны китапсыз тотмаска тырышам. Быел ике китабымны яңадан чыгардык. Тик менә типография бәяләре генә үскәннән-үсә, юкарак кәгазьгә күчәргә мәҗбүр булдык.

**– Сезнең әсәрләр күбрәк хатын-кыз язмышлары турында. Аларны укыган кеше нинди фикергә килергә тиеш? Сез нәрсә пропагандалыйсыз?**

– Сабырлык һәм зирәклек. Хәзерге яшьләргә зирәклек җитми. Минем өчен тормышта гаиләне саклау, балаларны ятим итмәү темасы беренче урында тора. Яшьләр пыр тузып талаша, һәрберсе үзен генә кайгырта, ә балаларны уйлаучы юк. Бала иртән әтисен дә, әнисен дә күреп, елмаеп уянырга тиеш. Ичмасам, хатын-кыз уйлансын иде бу хакта. Хәзер ирләр юк дәрәҗәсендә, аларны әнә 20 ел саен сугыш кыра, калганнары да, авырлыкларга түзә алмыйча, эчкечелеккә бирелә. Ир балаларны тәрбияләргә акыллы, каты куллы әтиләр җитми.

Быел яз Башкортстанга кайткач, бер ир-ат килеп керде. «Зифа апа, мине хәтерлисезме? Моннан 10 ел элек сезне күреп, китабыгызны укуым турында әйттем. Сез шулвакыт: «Укып үзеңә нинди файда алдың?» – дип сорадыгыз. Сез шул сорауны биргәннән соң китапны тагын бер кат укып чыктым. Мин яман тәртипсез идем. Хатыным, түзә алмыйча, ике балабызны алып, ташлап чыгып китте. Аларны кире алып кайттым, бүгенге көндә мин – 4 бала атасы, бик бәхетле кеше. Сезнең кайтканыгызны ишетеп, рәхмәт әйтергә килдем», – диде.

Рәхмәт сүзләре белдергән хатлар интернет аша да күп килә.